**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отмене карантина, установленного на территориях некоторых населенных пунктов Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством и выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить карантин, установленный в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных:

а) на территориях следующих населенных пунктов Республики Татарстан:

село Старый Убей Дрожжановского района;

деревня Малые Кибячи Сабинского района;

б) на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

улица Ленина в селе Татарские Ямалы Актанышского района;

улица Зеленая в поселке Бирюлинского зверосовхоза Высокогорского района;

улица Гагарина в селе Бегишево Заинского района;

улица Березовая в деревне Матюшино Лаишевского района;

улица Пионерская в селе Алан Тюлячинского района;

часть территории, используемой обществом с ограниченной ответственностью «Саба» для содержания молодняка крупного рогатого скота, у села Новый Мичан Сабинского района;

учебное хозяйство государственного бюджетного образовательного учреждения среднего профессионального образования «Спасский техникум отраслевых технологий» в городе Болгаре Спасского района.

2. Признать утратившими силу:

подпункт «а» пункта 1 Указа Президента Республики Татарстан от 22 июня 2015 года № УП-572 «Об установлении карантина на территориях некоторых населенных пунктов Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных»;

Указ Президента Республики Татарстан от 30 июля 2015 года № УП-689 «Об установлении карантина на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных»;

Указ Президента Республики Татарстан от 1 августа 2015 года № УП-696 «Об установлении карантина на территории села Старый Убей Дрожжановского района Республики Татарстан и на отдельной территории Спасского района Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент
Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
09 октября 2015 года
№ УП-977

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Чүпрәле районының Иске Үби авылы;

Саба районының Кече Кибәче авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Актаныш районының Татар Ямалысы авылындагы Ленин урамы;

Биектау районының Бөреле җәнлек совхозы поселогындагы Яшел урам;

Зәй районының Бигеш авылындагы Гагарин урамы;

Лаеш районының Матюшино авылындагы Каенлык урамы;

Теләче районының Алан авылындагы Пионерлар урамы;

Саба районы Яңа Мичән авылы янындагы «Саба» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориянең бер өлеше;

Татарстан Республикасы Спас районының Болгар шәһәрендәге «Спас тармак технологияләре техникумы» урта һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе уку-укыту хуҗалыгы.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында»

2015 елның 22 июнендәге ПУ-572 номерлы Указының 1 пункты «а» пунктчасы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 30 июлендәге ПУ-689 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Чүпрәле районының Иске Үби авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасы Спас районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 1 августындагы ПУ-696 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 09 октябрь
№ ПУ-977